ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

20.06.2019 п.г.т.Алексеевское № 260

**“Инфраструктур үсеш бүлегенең
муниципаль хезмәтләр күрсәтү
административ регламентларын
раслау турында” Алексеевск
муниципаль районы башкарма комитетының
28.12.2018 ел, 482 нче карарына үзгәрешләр
кертү хакында**

Татарстан Республикасында “Төзелешкә һәм территорияне планлаштыруга рөхсәт алу”ны максатчан модельгә кертү буенча чаралар планы (“юл картасы”) нигезендә

**карар бирәм:**

1. “Инфраструктур үсеш бүлегенең муниципаль хезмәтләр күрсәтү административ регламентларын раслау турында” Алексеевск муниципаль районы башкарма комитетының 28.12.2018 ел, 482 нче карарына үзгәрешләр кертергә:

1.1. Җир кишәрлегенең шәһәр төзү планын әзерләү һәм бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү административ регламентында (10 нчы кушымта) 2.4 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә;

«

| | | |
|---|---|---|
| 2.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү срогы, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы оешмага мөрәҗәгать итү кирәклеген исәпкә алып; муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату срогы, туктату мөмкинлеге Россия Федерациясе законнарында каралган очракта | Гаризаны теркәү вакытыннан алып 14 көн эчендә.<br>Җир кишәрлегенең элек расланган шәһәр төзү планы дубликатын бирү гариза килгән вакыттан алып 4 көн эчендә (ләкин 10 календарь көннән артык түгел) гамәлгә ашырыла.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү срогын туктату каралмаган. | РФ Шәһәр төзү кодексының 57.3 нче маддәсе, 6 нчы пункты |

».

1.2. Төзелешкә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү административ регламентында (6 нчы кушымта) 2.4 пунктны яңа редакциядә игълан итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| 2.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү срогы, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы оешмага мөрәҗәгать итү кирәклеген исәпкә алып; муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату срогы, туктату мөмкинлеге Россия Федерациясе законнарында каралган очракта | Төзелешкә рөхсәт бирү - 5 көн, гариза бирү көнен исәпкә алып.<br>Төзелешкә рөхсәт бирү срогын озайту – 5 көн.<br>Төзелешкә рөхсәт бирүгә үзгәрешләр кертү - биш көн.<br>Төзелешкә рөхсәт бирү дубликатын бирү – өч көн.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү срогын туктату каралмаган | РФ Шәһәр төзү кодексының 51 нче маддәсе, 11, 21.14 нче өлешләре |

».

2. Әлеге карарның үтәлешенә контрольлек итүне инфраструктур үсеш буенча башкарма комитет җитәкчесе урынбасары А.Н. Абакумовка йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Н.К. Кадыйров**